“Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы” муниципаль берәмлеге
“Лениногорск шәһәренең 13нче гомуми белем бирү мәктәбе”
муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе

| “Каралган”<br>Татар теле һәм әдәбияты<br>мәктәп методик берләшмәсе җитәкчесе<br>________ Р.Ш.Вильданова<br>Беркетмә №1 “ 18”.08.2025ел | “Килешенгән”<br>Укыту һәм тәрбия бирү эшләре буенча<br>директор урынбасары<br>________ Шайдуллина Р.Г.<br>“ 27 ”08.2025ел | “Раслыйм” 13 нче урта гомуми<br>белем бирү мәктәбе директоры<br>________Т.В.Павлов<br>Боерык №108-ОД<br>“ 28”08.2025ел |
|---|---|---|

# “Җырлап ачыла күңел”

дәрестән тыш эшчәнлек буенча

# ЭШ ПРОГРАММАСЫ

Укучыларның яше: 5-9 нчы сыйныфлар

Программаны тормышка ашыру вакыты: 1ел

Автор-төзүче: югары категорияле туган (татар )тел һәм әдәбият укытучысы Вильданова Р.Ш.

## I. Аңлатмалы язу

**Программаның актуальлеге һәм таләпләр**

Дәрестән тыш чараларның төп билгеләнеше – дәрестә каралган теоретик материалларны тирәнтен өйрәнү генә түгел, алган белемнәрен стандарт булмаган мәсьәләләр чишүдә куллана белү күнекмәләрен үстерү дә, мәсьәләләр белән эшләү культурасын тәрбияләү дә. Шулай ук балаларның яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып төзелергә һәм үткәрү формасы буенча укытуның дәрес системасыннан аермалы булырга тиеш. Әлеге “Җырлап ачыла күңел” түгәрәгенең программасы шуларны истә тотып тар төркемендә укучы балалар өчен төзелде.

Татар теле буенча оештырыла торган түгәрәк эшчәнлеге – бөтен укыту-тәрбия процессының аерылгысыз бер өлеше. Дидактик, методик һәм гамәли яктан дөрес оештырылган түгәрәк эше укучыларның белемнәрен киңәйтә. Түгәрәкнең педагогик яктан әһәмияте тагын шунда, укучылар тел буенча дәреслектә булмаган кызыклы материаллар белән танышалар, дәрестән тыш чараларда катнашу нәтиҗәсендә алган белемнәрен дәрестәге мөстәкыйль эш вакытында да файдалана алалар.

Рус телле балаларга татар теле  һәм әдәбиятын тирәнтен өйрәтүнең төп максаты – аларны бу телдә сөйләшергә, тыңлап аңларга, укырга һәм язарга, сүзләрне дөрес әйтә белергә өйрәтү, сүз байлыгын арттыру. Ә татар баласы үз телендә аралаша белә, аңа дәресләр кызыксыз булып тоелырга мөмкин. Шуңа күрә, укучыларны артык мәҗбүр итмичә, фән белән кызыксындыра белү, аларда татар телендә аралашу ихтыяҗы тудыру мөһим максат булып тора. Мин бу максатны тормышка ашыру өчен татар халык мәдәниятына, традицияләренә мөрәҗәгать итәргә булдым. Халык традицияләрен белем бирү прцессында куллануның тәрбияви роле дә бик зур. Һәр халыкның үзенә хас традицияләре бар, әлбәттә. Ләкин традицияләр төрле булуга карамастан, максаты барысының да бер: киләчәк буынга тиешле тәрбия бирү. Халыкның иң күркәм гореф-гадәт һәм йолаларының милләтара мөнәсәбәтләрнең бүгенге катлаулы чорында дуслык, татулык урнаштыруда, яшь буынга белем һәм тәрбия бирү эшчәнлегендә терәк булып торуын һәркем ачык белә.

Татарстан Республикасында яшәүче һәр милләт кешесенә, үз халкы тарихыннан тыш, шушы төбәктә төп халык булып саналган татар халкы мәдәниятен, гореф-гадәтләрен, тарихи үткәнен, бүгенгесен, киләчәген белү зарур. Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш. Шуңа күрә мин  ““Җырлап ачыла күңел”  дип исемләнгән түгәрәк эшенең программасы төзергә уйладым.

**Программаның максаты һәм бурычлары**

Татарстан җирендә яшәп, рус мохитендә тәрбияләнеп, татар халкының тормыш-көнкүрешен күреп үсүче балаларга татар халкының бай әдәбияты үрнәкләре аша татар теленең бөеклегенә инандыру, телне өйрәнү мохитен тудыру, татар телендә аралашырга, үз фикерен белдерергә өйрәтү.

1. Укучыларның сүзлек хәзинәсен баету, аралаша белү күнекмәләрен камилләштерү, үзара дустанә хезмәттәшлек булдыру;
2. Танып-белү эшчәнлеген, иҗади фикерләү сәләтен камилләштерү;
3. Төркем эчендә эшли, фикерләрне тыңлый белү;
4. Укучыларны эзләнү-тикшеренү эшчәнлегенә тарту, нәтиҗә ясарга юнәлеш бирү.

Программа 34сәгатькә исәпләнгән, атнасына 1 тапкыр

**II. Дәрестән тыш эшчәнлек курсының эчтәлеге**

Түгәрәкнең эчтәлеге һәм планы укучыларның кызыксынуларыннан, яшь үзенчәлекләреннән чыгып төзелә.

Түгәрәк эшләренең укучыларга белем һәм тәрбия бирүдә аерым таләпләре дә бар:

- Укучылар түгәрәккә теләп язылырга, ягъни ирекле рәвештә язылырга тиеш;
- Түгәрәкне үткәрү өчен метод һәм алымнарны сайлый белергә кирәк;
- Укучылар алган биремнәр авыр һәм катлаулы булмаска тиеш;
- Түгәрәк системалы рәвештә үткәрелергә тиеш.

**1. Татар халык җырлары.** Укучыларны татар халык җырлары белән таныштыру, аларның эчтәлеген аңлату.

**2. Көз турында җырлар.** ( Укытучы, әниләр көненә багышланган җырлар)

**3. Кыш темасына җырлар.** (Кыш бабай , Яңа ел турында җырлар)

**4. Яз турында җырлар.** Язгы бәйрәмнәрне үз эченә алган җырлар.

**5. Шаян җырлар.** Уен җырлары. Такмаклар.

**6. Табигать, туган як турында җырлар.** Татар халкы белән кулга-кул тотынып яшәргә әзерләнүче һәр кеше бу халыкның бәйрәмнәрен, традицияләрен аңларга, хөрмәт итәргә, әдәбият-сәнгать вәкилләренең иҗади казанышлары белән үзенең рухи үсешен баета алу мөмкинлегеннән файдаланырга тиеш.

## III. Курсның планнаштырылган нәтиҗәләре

**Шәхси:**

Гомуми белем бирү мәктәбен төгәлләгәндә, укучының үзенә һәм үзенең әйләнә-тирәсендәге кешеләргә, тормыштагы яшәеш проблемаларына карата түбәндәге **шәхси кыйммәтләре формалашкан булуы күзаллана**:

- шәхесара һәм мәдәниятара аралашуда татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге тудыру;
- әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау;
- текстлардагы төрле тормыш ситуацияләренә һәм геройларның гамәлләренә гомүмкешелек нормаларыннан чыгып бәя бирү;
- «гаилә», «туган ил», «мәрхәмәтлелек» төшенчәләрен кабул итү, «башкаларга карата түземлелек, кайгыртучанлык», «кеше кадерен белү» кебек хисләр формалашу.

**Метапредмет:**

Урта белем бирү баскычында телгә өйрәтү, укучыларның фикер йөртү, интеллектуаль һәм иҗади сәләтләрен үстерүгә, шулай ук, реаль тормышта туган проблемаларны хәл итү өчен кирәк булган универсаль уку гамәлләрен (***танып белү, регулятив, коммуникатив)*** формалаштыруга хезмәт итә.

Укучыларда мәгълүмати җәмгыятьтә яшәү һәм эшләү өчен кирәкле күнекмәләр үстерелә. Укучылар, презентацион материаллар әзерләп, зур булмаган аудитория алдында чыгыш ясарга өйрәнә*; у*кучыларда, компьютер яисә ИКТ нең башка чаралары белән эш иткәндә, сәламәтлеккә зыян китерми торган эш алымнарын куллана алу күнекмәләре формалаша.

Танып белү нәтиҗәләре:

- фикерләүне үстерү белән бәйле психик функцияләр: логик фикерләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен табу, индуктив, дедуктив фикерли белү;
- объектларны чагыштыру, классификацияләү өчен уртак билгеләрне билгеләү;
- төп мәгълүматны аеру, укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирә белү.

Регулятив нәтиҗәләр:

- уку хезмәтендә үзеңә максат куя, бурычларны билгели белү;
- эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра, нәтиҗәле эш алымнарын таба белү;
- укудагы уңышларның, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү;
- ихтыяр көче, максатчанлык, активлык кебек сәләтләрне формалаштыру;

Коммуникатив нәтиҗәләр:

- әңгәмәдәшеңнең фикерен тыңлый, аңа туры килерлек җавап бирә белү;
- әңгәмәдәш белән аралашу калыбын төзү;
- аралаша белү сәләтен үстерү (аралашучанлык, хислелек, эмпатия хисләре);
- парларда һәм күмәк эшли белү;
- мәгълүматны туплау өчен, күмәк эш башкару;
- әңгәмәдәшең белән сөйләшүне башлый, дәвам итә, тәмамлый белү.

**Курсның предмет нәтиҗәләре:**

Тыңлап аңлау:

- төрле жанрдагы халык авыз иҗаты әсәрләрен тыңлап аңлау күнегүләрен үти белү;

- сүзләрне, җөмләләрне аңлап тәрҗемә итә белү; тәкъдим ителгән текстны тыңлап, эчтәлеге буенча сорау бирә, сорауларга җавап бирә белү;
- зур булмаган аутентив яки адаптацияләнгән халык авыз иҗаты әсәрләреннән өзекләрне, тыңлап аңлап, эчтәлеге буенча фикереңне әйтә, аралашуга чыга белү;
- сыйныфташларыңның сөйләмен тыңлап аңлау һәм аларга үз фикереңне аңлата белү, алар белән әңгәмә кору, әңгәмәдә катнаша белү.

Диалогик сөйләм:

- сорау, җавап, килешү-килешмәү, шикләнү һәм башка репликаларны дөрес кулланып, әңгәмә кору, сөйләшә белү;
- парда, төркемдә сөйләшү барышында үз фикереңне аңлата, раслый, дәлилли белү, ситуация аңлашылмаганда, сорау биреп, сөйләм барышын ачыклый белү;

Монологик сөйләм:

- халык авыз иҗаты әсәрләре үрнәгендә әкиятләр,табышмаклар һ.б. төзи алу һәм аның эчтәлеген сөйли белү;
- конкрет ситуациягә үз карашыңны әйтә, төрле вакыйгалар, яңалыкларны хәбәр итә белү;

**IV. “Җырлап ачыла күңел”дәрестән тыш эшчәнлек курсының календарь-тематик планы**

| | Тема | Сәг саны | Үткәрү формасы | Электрон ресурслар |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Татар халык җырлары | 1 | түгәрәк өстәл | Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 2 | Рәхәт үтте җәебез. Көзге яфраклар җыры. | 1 | экскурсия | Татарский язык: большой электронный свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet |
| 3 | Сентябрь алмалары. | 1 | түгәрәк өстәл | Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 4 | Сентябрь алмалары. Көз килә. | 1 | түгәрәк өстәл | |
| 5 | Әбием-әбекәем. Чәй эчәбез бергәләп. | 1 | түгәрәк өстәл | Татарский язык: большой электронный свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet |
| 6 | Укытучы турында шигырьләр .Укытучым. | 1 | | Татарский язык: большой электронный свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet |
| 7 | Килә коштай очасы. Чыпчык | 1 | уен | В.Хәйруллина “Балачак җырлары” |
| 8 | Күңелле сәяхәт | 1 | уен | Сборник анимационных фильмов, созданных объединением «Татармультфильм» // URL: www.tatarcartoon.ru |
| 9 | Маэмай. | 1 | презентация | Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 10 | Шаян җырлар | 1 | уен | В.Хәйруллина “Балачак җырлары” |
| 11 | Әниләр бәйрәме. Рәхмәт, әнием. Әниләр көне | 1 | түгәрәк өстәл | Татарский язык: большой электронный свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet |
| 13 | Рәхмәт, әнием. Әниләр турында җырлар | 1 | концерт | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 14 | Карлар ява | 1 | уен | |
| 15 | Чыршы янында. Чыршыкай -купшыкай | 1 | уен | Сборник анимационных фильмов, созданных объединением «Татармультфильм» // URL: www.tatarcartoon.ru |
| 16 | Хуш киләсең, Яңа ел. Бәйрәм кичәсе | 1 | музыкаль кичә | |
| 17 | Кышкы урманга килдек. | | уен | |
| 18 | Кар бөртекләре оча | 1 | түгәрәк өстәл | Интерактивная мультимедийная энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 19 | Иң шәп бабай | 1 | түгәрәк өстәл | |
| 20 | Мин шофер | 1 | түгәрәк өстәл | Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 21 | Нәни музыкант | 1 | уен | |
| 22 | Әтиемә | 1 | | Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 23 | Солдатлар | 1 | презентация | В.Хәйруллина “Балачак җырлары” |
| 24 | Рәхмәт, әнием | 1 | | Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 25 | Әниләргә сөю бүләк итик | 1 | түгәрәк өстәл | |
| 26 | Язгы тамчы. | 1 | уен | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 27 | Кояш көлә | 1 | түгәрәк өстәл | |
| 28 | Зәңгәр күл | 1 | түгәрәк өстәл | Интерактивная мультимедийная энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 29 | Күңелле сәяхәт | 1 | уен | |
| 30 | Гүзәл туган ягыбыз | 1 | түгәрәк өстәл | |
| 31 | Сынамышлар,санамышлар. | 1 | түгәрәк өстәл | Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru |
| 32 | Такмаклар | 1 | уен | |
| 33 | Хуш киләсең , җәй | 1 | экскурсия | Сборник анимационных фильмов, созданных объединением «Татармультфильм» // URL: www.tatarcartoon.ru |
| 34 | Уеннар. Табигать матурлыгы. | 1 | проект эше яклау | Нәкый Исәнбәт “Балалар фольклоры» |

## V. Интернет ресурс һәм китап исемлеге


1.Сборник анимационных фильмов, созданных объединением «Татармультфильм» // URL: www.tatarcartoon.ru
2. Интерактивная мульт-ая энциклопедия // URL: www.balarf.ru
3. Татарский язык: большой электронный свод // URL: http://www.antat.ru/ru/tatzet
4. Нәкый Исәнбәт “Балалар фольклоры»
5. В.Хәйруллина “Балачак җырлары”